**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода, ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе, Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.09.2017 Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы № 200пи

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
муниципаль учреждениеләре
хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 27 июнендәге 438 нче номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләвен арттыру турында», 2017 елның 2 августындагы 538 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» карарларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренә, хезмәт өчен түләү шартлары Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2010 елның 24 августындагы 156пи номерлы «Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» җайга салына торган карары белән, 2017 елның 1 июленнән 1 580,0 сум күләмендә өстәмә түләү билгеләргә.

2. Әлеге өстәмә түләүләрнең ай саен, бу чорда эшләнелгән вакытка пропорциональ рәвештә түләнүен билгеләргә.

3. Әлеге карар, «ярдәмче составның техник башкаручылары һәм артистлары вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеменә караган мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләре хезмәткәрләреннән һәм эшче мәдәният, сәнгать һәм кинематография һөнәрләренең һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләреннән тыш, хезмәт хакынын артуы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013-2018 елларда Татарстан Республикасында фаразланган уртача хезмәт хакы белән Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең уртача хезмәт хакы нисбәте зурлыгының динамикасын раслау турында» 2012 елның 20 декабрендәге 2291-р номерлы боерыгы нигезендә билгелэнуче Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренә кагылмый.

4. Әлеге карар 2017 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5 Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайты Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталынын" Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru. урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин